*Муниципаль тур*

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының
татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар теленнән
олимпиада биремнәре**

***(2017/2018 нче уку елы)***

**V сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл -56**

**I. Таблицаны тутырып бетерегез.**

| 1 нче мәгънәсе белән җөмлә | Омоним сүз | 2 нче мәгънәсе белән җөмлә |
|---|---|---|
| Ай, нинди хәйләкәр бабай, дип уйлады Илсөяр эченнән генә. *(Г. Гобәй)* | ... | Казаннан кайтканыңа хәзер биш ай бардыр инде. *(Г. Камал)* |
| Бай тарихлы Казан, данлы Казан! *(Ә. Ерикәй)* | бай | ... |
| ... | ... | Конкурска йомгак ясалды. |
| Яңа бистәнең атаклы көзге пычраклары башланды. *(Ә. Фәйзи)* | көзге | ... |
| ... | ... | Үзе язган әйбернең басма китап рәвешендә чыгуы Габдуллада горурлык хисләре тудырды. *(Ә. Фәйзи)* |

**II. Күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгеләгез.**

1. Малайның бөтен тәненә рәхәт җылылык йөгерде.

2. Чәнечкеле суык кызның аякләрен чеметә.

3. Менә шул болытлар урман артына таба салмак кына агалар.

4. Сүрән кояш болыт арасыннан җиргә бага.

5. Тын гына ак кар төшә.

6. Су өстендә, рәшә булып, нәни дулкыннар уйнады. *(Р. Мөхәммәдиев)*

**III. Биремнәрне үтәгез.**

1. Бирелгән җөмләдә ике аваз кушылмасын белдергән хәрефләр булган сүзләрне күрсәтегез.

*Шаян исемле төлке баласы уянды. (Ф. Зариф)*

2. Бирелгән җөмләдән сүз ясагыч кушымча ярдәмендә ясалган сүзләрне язып алыгыз.

*Акыллы кош агач куышында тимерче алачыгы ачып җибәрде, тук-тук итеп, нарат күркәләре ярды, орлыгы белән Тиенне сыйлады. (А. Хәсәнов)*

3. *– Ник мендең син минем алмагачка,*

*Башкаеңны салып юләргә.*

*– Бер алмагыз өзелеп төшкән.*

*Мендем, бабай, шуны эзләргә. (З. Нури)* дигән шигырь юлларыннан хикәя фигыльләрне табып, заманын, зат-санын билгеләгез.

4. *Кара төлкеләр бик сирәк булалар, тиреләре дә кыйммәтрәк йөри (В. Бианки)* җөмләсеннән сыйфатларны табып, дәрәҗәләрен күрсәтегез.

5. *Мондый чакларда кенәри өздереп сайрый. (Н. Каштанов)* җөмләсендә басымы *беренче иҗеккә* төшкән сүзне табыгыз.

**IV. Бирелгән сүзләрне тәрҗемә итеп, аларның антонимнарын шакмакларга языгыз.**

| | |
|---|---|
| | |

много –

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

выше –

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

раньше –

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

дальше –

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

быстрее –

**V. Туган ил турында 5 мәкаль уйлап языгыз.**